ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

28.06.2024 № 601

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге хакында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 31 августындагы 744 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге хакында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 31 августындагы 744 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының планлаштырылган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм индивидуаль торак төзелеше объектын яисә бакча йортын җир кишәрлегендә урнаштыру мөмкинлеге хакында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентының 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктындагы 1 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5.1. Индивидуаль торак төзелеше объектын ("Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"

2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән тыш) яисә бакча йортын төзү, реконструкцияләү максатларында төзүче тапшыра:».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин